ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 апреля 2021г. № 2862

Башкарма комитетның 2020 елның 30 октябрендәге 5732 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 30 октябрендәге 5732 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын оештыру һәм үткәрү һәм тиешле республика һәм бөтенроссия конкурсларында катнашуга тәкъдим итү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе | 2021-2023 еллар | Муниципаль хокукый акт кабул итү һәм «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәре» конкурсын үткәрү | + | + | + | + | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) | 100,0 (муниципаль бюджет) |

2) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектә 15 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15. | Җирле үзидарә көненә һәм Финансистлар көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе, финанс идарәсе | 2021-2023 еллар | Муниципаль хокукый актлар кабул итү һәм Җирле үзидарә көненә һәм Финансистлар көненә багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | + | + | + | + | 66,0 (муниципаль бюджет) | 66,0 (муниципаль бюджет) | 66,0 (муниципаль бюджет) |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов